Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Янил авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 март, 2024 ел № 11

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр бистәсе торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы Бөяр бистәсе гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Янил авыл җирлеге Уставы нигезендә Янил авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 4 апреленә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Бөяр бистәсе гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Бөяр бистәсе, Чәчәкле урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан торак йортта үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Бөяр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге Бөяр бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокпы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Бөяр бистәсендә урам юл челтәрен тоту, килешү буенча түләү;

2) Бөяр бистәсенә энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм килешү буенча түләү

2023 елның 23 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны

ремонтлау (Бөяр бистәсенә энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөяр бистәсендә урам юл челтәрен карап тоту, проект-смета документларын эшләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов